**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Нижнекамский городской**
**С О В Е Т**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
тел./факс (8555) 42-51-76, 42-47-06

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама шәһәр**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 42-51-76, 42-47-06

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 30** **2015 елның 15 июне**

**Түбән Кама шәһәр Советының "Шәһәрдә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан тәкъдим итү һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан шәһәрнең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр , бирү турындагы" 2014 нче елның 30 нчы октябрендәге 29 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Президентының 2014 нче елның 23 нче июненнән 460 нчы санлы «Керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Указы, Түбән Кама шәһәре Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2014 нче елның 30 нчы октябрендә Түбән Кама шәһәр Советының 29 нчы номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Түбән Кама шәһәре муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 6 нчы пунктның «в» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «в) һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, шулай ук һәр алыш-биреш буенча җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча ул, аның хатыны (ире) һәм (яки) балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) һәм әлеге алыш-бирешләр башкарылган акчалар алу чыганаклары турында;

1.2. 8 нче пунктта «җирле үзидарә органы җитәкчесе исеменә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 13нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «13. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлеген, башка күчемсез милек объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешен, пайларын) сатып алу буенча алыш-биреш эшләре башкарылган акчалар чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, Түбән Кама муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге мәгълүматлар рәсми сайтта аларның запрослары буенча бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары тарафына тапшырыла».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре мэры А. Р. Метшин